# ЗАКОН
## РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Об участии граждан в охране общественного порядка в Республике Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
24 декабря 2014 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

1. Настоящий Закон принят в соответствии с Федеральным законом от 2 апреля 2014 года № 44-ФЗ «Об участии граждан в охране общественного порядка» (далее – Федеральный закон) и регулирует вопросы, связанные с организацией участия граждан в охране общественного порядка на территории Республики Татарстан.

2. Настоящий Закон устанавливает образец и порядок выдачи удостоверения народного дружинника, образец отличительной символики народного дружинника, порядок создания и деятельности координирующих органов (штабов) народных дружин.

Статья 2. **Основные термины и понятия**

В настоящем Законе основные термины и понятия используются в том же значении, что и в Федеральном законе.

Статья 3. **Правовая основа участия граждан в охране общественного порядка**

Правовую основу участия граждан в охране общественного порядка составляют Конституция Российской Федерации, общепризнанные принципы и нормы международного права, федеральные конституционные законы, Федеральный закон, другие федеральные законы и иные нормативные правовые акты Российской Федерации, Конституция Республики Татарстан, настоящий Закон и иные нормативные правовые акты органов государственной власти Республики Татарстан, муниципальные нормативные правовые акты.

Статья 4. **Полномочия Кабинета Министров Республики Татарстан в сфере регулирования участия граждан в охране общественного порядка**

1. Кабинет Министров Республики Татарстан в сфере регулирования участия граждан в охране общественного порядка осуществляет следующие полномочия:

1) принимает нормативные правовые акты в сфере регулирования участия граждан в охране общественного порядка;

2) оказывает поддержку гражданам и их объединениям, участвующим в охране общественного порядка;

3) создает Республиканский штаб по координации деятельности народных дружин в Республике Татарстан;

4) размещает на своем официальном сайте в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет», а также в средствах массовой информации общедоступную информацию о лицах, пропавших без вести, месте их предполагаемого поиска, контактную информацию координаторов мероприятий по поиску лиц, пропавших без вести, иную общедоступную информацию, необходимую для эффективного поиска лиц, пропавших без вести;

5) осуществляет информационно-методическую поддержку граждан и их объединений, участвующих в охране общественного порядка;

6) осуществляет личное страхование народных дружинников на период их участия в проводимых органами внутренних дел (полицией) или иными правоохранительными органами мероприятиях по охране общественного порядка;

7) осуществляет иные полномочия в сфере регулирования участия граждан в охране общественного порядка, предусмотренные федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

2. Порядок осуществления полномочий, установленных в настоящей статье, определяется Кабинетом Министров Республики Татарстан в соответствии с законодательством.

Статья 5. **Полномочия органов местного самоуправления в сфере регулирования участия граждан в охране общественного порядка**

1. Органы местного самоуправления в Республике Татарстан (далее – органы местного самоуправления) в соответствии с полномочиями, установленными Федеральным законом, Федеральным законом от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», другими федеральными законами, настоящим Законом и муниципальными правовыми актами, оказывают поддержку гражданам и их объединениям, участвующим в охране общественного порядка, создают условия для деятельности народных дружин.

2. В целях содействия гражданам, участвующим в поиске лиц, пропавших без вести, органы местного самоуправления размещают на своих официальных сайтах в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет», а также в средствах мас-

совой информации общедоступную информацию о лицах, пропавших без вести, месте их предполагаемого поиска, контактную информацию координаторов мероприятий по поиску лиц, пропавших без вести, иную общедоступную информацию, необходимую для эффективного поиска лиц, пропавших без вести.

Порядок размещения такой информации определяется муниципальными правовыми актами.

3. Органы местного самоуправления определяют порядок направления рекомендаций органов местного самоуправления гражданам, участвующим в поиске лиц, пропавших без вести, для решения вопросов формирования организованных групп, определения маршрута и места предполагаемого поиска, иных вопросов.

4. Представительные органы соответствующих муниципальных образований в Республике Татарстан устанавливают границы территории, на которой может быть создана народная дружина.

5. Органы местного самоуправления могут выделять средства на финансирование материально-технического обеспечения деятельности народных дружин, предоставлять народным дружинам помещения, технические и иные материальные средства, необходимые для осуществления их деятельности.

6. Органы местного самоуправления за счет средств соответствующих местных бюджетов могут осуществлять материальное стимулирование деятельности народных дружинников, предоставлять народным дружинникам проездные билеты на все виды общественного транспорта городского, пригородного и местного сообщения (за исключением такси) в пределах территории муниципального образования, устанавливать дополнительные льготы и компенсации, гарантии правовой и социальной защиты для народных дружинников и членов их семей, а также использовать иные формы их материальной заинтересованности, не противоречащие федеральному законодательству и законодательству Республики Татарстан.

Порядок предоставления органами местного самоуправления льгот и компенсаций народным дружинникам определяется муниципальными правовыми актами.

Статья 6. **Координирующие органы (штабы) народных дружин**

1. В целях осуществления координации деятельности народных дружин на территории Республики Татарстан и их взаимодействия с органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления, а также органами внутренних дел (полицией) и иными правоохранительными органами создается Республиканский штаб по координации деятельности народных дружин в Республике Татарстан (далее – Республиканский штаб).

2. Республиканский штаб создается Кабинетом Министров Республики Татарстан и является постоянно действующим коллегиальным органом. Структура и состав Республиканского штаба утверждаются Кабинетом Министров Республики Татарстан.

3. Основными задачами Республиканского штаба являются:

1) координация деятельности народных дружин по вопросам содействия органам внутренних дел (полиции) и иным правоохранительным органам в охране общественного порядка;

2) обобщение и анализ информации о деятельности народных дружин и проведение обучающих семинаров для командиров народных дружин в Республике Татарстан;

3) разработка рекомендаций для народных дружин по вопросам содействия органам внутренних дел (полиции) и иным правоохранительным органам в охране общественного порядка;

4) иные задачи, установленные Кабинетом Министров Республики Татарстан.

4. В целях выполнения основных задач Республиканский штаб осуществляет следующие функции:

1) рассмотрение вопросов и предложений, связанных с координацией деятельности народных дружин и содействием органам внутренних дел (полиции) и иным правоохранительным органам в охране общественного порядка;

2) принятие в пределах своей компетенции решений;

3) оформление, выдача и замена удостоверений командиров народных дружин, их заместителей;

4) иные функции, установленные Кабинетом Министров Республики Татарстан.

5. В целях взаимодействия и координации деятельности народных дружин на территориях соответствующих муниципальных образований органы местного самоуправления могут создавать координирующие органы (штабы) народных дружин.

6. Порядок создания и деятельности координирующих органов (штабов) народных дружин установлен в приложении 1 к настоящему Закону.

## Статья 7. **Удостоверение и отличительная символика народного дружинника**

1. Народные дружинники при участии в охране общественного порядка должны использовать отличительную символику народного дружинника в виде форменной одежды и (или) нарукавной повязки и иметь при себе удостоверение народного дружинника установленного образца согласно приложениям 2 и 4 к настоящему Закону.

2. Порядок выдачи удостоверения народного дружинника установлен в приложении 3 к настоящему Закону.

3. Форменная одежда народного дружинника представляет собой унифицированный по существенным внешним признакам элемент верхней одежды, предназначенный для ношения народным дружинником при участии в мероприятиях по охране общественного порядка.

4. Форменная одежда и (или) нарукавная повязка выдаются народному дружиннику командиром народной дружины при заступлении на дежурство.

5. При прекращении членства в народной дружине или по истечении срока действия удостоверения оно подлежит сдаче командиру народной дружины.

6. Удостоверение народного дружинника, форменная одежда и нарукавная повязка изготавливаются за счет средств народных дружин.

Статья 8. **Материальное стимулирование и личное страхование народных дружинников**

1. Органы государственной власти Республики Татарстан за счет средств бюджета Республики Татарстан могут осуществлять материальное стимулирование деятельности народных дружинников.

2. Кабинет Министров Республики Татарстан осуществляет личное страхование народных дружинников на период их участия в проводимых органами внутренних дел (полицией) или иными правоохранительными органами мероприятиях по охране общественного порядка.

3. Страховые суммы выплачиваются при наступлении следующих страховых случаев в период участия народного дружинника в проводимых органами внутренних дел (полицией) или иными правоохранительными органами мероприятиях по охране общественного порядка:

1) гибель народного дружинника;

2) установление народному дружиннику инвалидности;

3) получение народным дружинником телесного повреждения.

Статья 9. **Меры поощрения граждан, участвующих в осуществлении охраны общественного порядка, применяемые органами государственной власти и органами местного самоуправления**

1. Народные дружинники за активное участие в осуществлении охраны общественного порядка и борьбе с правонарушениями могут поощряться органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления путем:

1) объявления благодарности;

2) выдачи денежной премии;

3) награждения ценным подарком;

4) награждения почетными грамотами органов государственной власти Республики Татарстан, почетными грамотами органов местного самоуправления.

2. За особые заслуги в выполнении своего общественного долга и проявленные при этом мужество и героизм граждане, участвующие в осуществлении охраны общественного порядка, могут быть представлены к государственным наградам Российской Федерации и государственным наградам Республики Татарстан в соответствии с законодательством.

3. Меры поощрения применяются органами государственной власти Республики Татарстан и органами местного самоуправления из средств соответствующих бюджетов, добровольных пожертвований физических и юридических лиц и других источников, не запрещенных законом.

Статья 10. **Признание утратившими силу отдельных законодательных актов (положений законодательных актов) Республики Татарстан**

Со дня вступления в силу настоящего Закона признать утратившими силу:

1) Закон Республики Татарстан от 1 ноября 2005 года № 107-ЗРТ «Об участии граждан в обеспечении общественного порядка в Республике Татарстан»;

2) Закон Республики Татарстан от 8 ноября 2007 года № 52-ЗРТ «О внесении изменения в Закон Республики Татарстан «Об участии граждан в обеспечении общественного порядка в Республике Татарстан»;

3) Закон Республики Татарстан от 23 июня 2008 года № 25-ЗРТ «О внесении изменений в статьи 7 и 17 Закона Республики Татарстан «Об участии граждан в обеспечении общественного порядка в Республике Татарстан»;

4) статью 17 Закона Республики Татарстан от 12 июня 2014 года № 53-ЗРТ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан».

Статья 11. **Вступление в силу настоящего Закона**

1. Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан привести свои нормативные правовые акты в соответствие с настоящим Законом, а также принять нормативные правовые акты, обеспечивающие реализацию настоящего Закона, в шестимесячный срок со дня его вступления в силу.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
16 января 2015 года
№ 4-ЗРТ

Приложение 1
к Закону Республики Татарстан
«Об участии граждан
в охране общественного
порядка в Республике Татарстан»

**Порядок создания и деятельности координирующих органов (штабов) народных дружин**

1. Настоящий Порядок в соответствии со статьей 13 Федерального закона определяет порядок создания и деятельности координирующих органов (штабов) народных дружин.

2. Координирующие органы (штабы) народных дружин могут создаваться органами государственной власти Республики Татарстан и органами местного самоуправления в целях взаимодействия и координации деятельности народных дружин.

3. Решение о создании координирующего органа (штаба) народных дружин, утверждение его состава оформляются правовым актом органа, принявшего решение о его создании.

4. Координирующий орган (штаб) народных дружин осуществляет свою деятельность в соответствии с положением, утверждаемым органом, принявшим решение о его создании.

5. В состав координирующего органа (штаба) народных дружин могут входить представители органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, территориальных органов федерального органа исполнительной власти в сфере внутренних дел, а также руководители общественных объединений правоохранительной направленности и командиры народных дружин. В состав координирующего органа (штаба) народных дружин при необходимости могут включаться иные лица.

6. Координирующий орган (штаб) народных дружин возглавляет руководитель координирующего органа (начальник штаба) народных дружин, назначаемый из числа должностных лиц органа, принявшего решение о создании координирующего органа (штаба) народных дружин.

7. Координирующий орган (штаб) народных дружин:

1) организует взаимодействие народных дружин с органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления и правоохранительными органами по вопросам охраны общественного порядка;

2) рассматривает основные вопросы деятельности народных дружин, выявляет проблемы, возникающие в процессе деятельности народных дружинников, вырабатывает предложения по их решению;

3) привлекает к своей работе представителей заинтересованных органов и организаций и других специалистов;

4) осуществляет другие полномочия в соответствии с законодательством.

Приложение 2
к Закону Республики Татарстан
«Об участии граждан
в охране общественного
порядка в Республике Татарстан»

**Описание и образец удостоверения народного дружинника**

1. Удостоверение народного дружинника представляет собой книжечку размером (в развернутом виде) 65 х 200 мм. Обложка удостоверения изготавливается из материала красного цвета. Внутренние вклейки удостоверения выполняются из бумаги белого цвета.

2. На правой части лицевой стороны удостоверения в верхней части прописными буквами золотистого цвета нанесена надпись в две строки

«ХАЛЫК ДРУЖИНАЧЫСЫ
ТАНЫКЛЫГЫ»,

ниже горизонтальная линия золотистого цвета.

Ниже указанной горизонтальной линии прописными буквами золотистого цвета нанесена надпись в две строки

«УДОСТОВЕРЕНИЕ
НАРОДНОГО ДРУЖИННИКА».

3. На левой части внутренней стороны удостоверения:

вверху нанесена одна горизонтальная линия, под которой расположены слова «(халык дружинасының исеме)»;

под ними в центре – надпись «ХАЛЫК ДРУЖИНАСЫ»;

под ней по центру – надпись «Таныклык № __»;

ниже в три строки – слова «Фамилиясе», «Исеме», «Атасының исеме», рядом с каждым словом с правой стороны располагается горизонтальная линия;

под этими словами располагаются в одной горизонтали две линии, под левой – слово «(вазыйфасы)», под правой – «(имза)»;

в нижней части в две строки размещены слова:

«20 ___ елның ______ кадәр гамәлдә
20 ___ елның ______ кадәр озайтылды».

4. На правой части внутренней стороны удостоверения:

вверху в центре нанесена надпись «НАРОДНАЯ ДРУЖИНА»;

под ней – одна горизонтальная линия, под которой расположены слова «(наименование народной дружины)»;

под ними по центру – надпись «Удостоверение №__»;

ниже указанных слов слева наклеивается фотография (анфас) размером 2,5 х 3 см;

справа от фотографии в три строки – слова «Фамилия», «Имя», «Отчество», рядом с каждым словом с правой стороны располагается горизонтальная линия;

под этими словами располагаются в одной горизонтали две линии, под левой – слово «(должность)», под правой – «(подпись)»;

под фотографией оставлено место для печати и нанесены прописные буквы «М.П.»;


в нижней части в две строки размещены слова:

«Действительно до ____________ 20___ года

Продлено до __________________ 20___ года».

5. После заполнения всех необходимых реквизитов удостоверение заверяется печатью органа местного самоуправления: печать ставится с захватом правого нижнего угла фотографии и части строки с подписью командира народной дружины.

6. Образец удостоверения народного дружинника




**Левая часть внутренней стороны**

**Правая часть внутренней стороны**

| Левая часть | Правая часть |
|---|---|
| ______________________ (халык дружинасының исеме) | НАРОДНАЯ ДРУЖИНА |
| ХАЛЫК ДРУЖИНАСЫ | ______________________ (наименование народной дружины) |
| Таныклык № ____ | место для фотографии Удостоверение № _____ |
| Фамилиясе ____________ | Фамилия ____________ |
| Исеме ____________ | Имя ____________ |
| Атасының исеме ____________ | Отчество ____________ |
| ____________ (вазыйфасы) ____________ (имза) | М.П. ____________ (должность) ____________ (подпись) |
| 20 _____ елның __________ кадәр гамәлдә | Действительно до __________ 20 _____ года |
| 20 _____ елның __________ кадәр озайтылды | Продлено до __________ 20 _____ года |

Приложение 3
к Закону Республики Татарстан
«Об участии граждан
в охране общественного
порядка в Республике Татарстан»

**Порядок выдачи удостоверения народного дружинника**

1. Настоящий Порядок в соответствии со статьей 16 Федерального закона устанавливает порядок выдачи удостоверения народного дружинника.

2. Оформление удостоверения народного дружинника производится органами местного самоуправления поселения, городского округа по единому образцу, утвержденному Законом Республики Татарстан «Об участии граждан в охране общественного порядка в Республике Татарстан».

3. Удостоверение народного дружинника выдается сроком на три года на основании письменного заявления гражданина.

Срок действия удостоверения продлевается на три года.

4. Удостоверение народного дружинника подписывается уполномоченным должностным лицом органа местного самоуправления и заверяется печатью органа местного самоуправления.

5. Удостоверение народного дружинника вручается народному дружиннику под роспись, как правило, в торжественной обстановке и в присутствии членов народной дружины.

6. Учет выданных удостоверений ведется органом местного самоуправления в журнале регистрации удостоверений народных дружинников.

7. В случае утраты или порчи удостоверения народного дружинника, истечения срока его действия или изменения персональных данных народного дружинника производится замена удостоверения. При этом ранее выданное удостоверение (за исключением случаев его утраты) сдается командиром народной дружины в соответствующий орган местного самоуправления.

8. В случае исключения народного дружинника из народной дружины удостоверение народного дружинника сдается командиром народной дружины в соответствующий орган местного самоуправления.

Приложение 4
к Закону Республики Татарстан
«Об участии граждан
в охране общественного
порядка в Республике Татарстан»

**Описание и образец отличительной символики народного дружинника**

1. Форменная одежда народного дружинника представляет собой жилет синего цвета со встроенными светоотражающими элементами, на который наносятся надписи:

1) на фронтальной стороне справа на уровне нагрудного кармана – слова «НАРОДНАЯ ДРУЖИНА» прописными буквами высотой 10 мм;

2) на фронтальной стороне слева на уровне нагрудного кармана – слова «ХАЛЫК ДРУЖИНАСЫ» прописными буквами высотой 10 мм;

3) на тыльной стороне – слова «НАРОДНАЯ ДРУЖИНА» прописными буквами высотой 60 мм;


под ними горизонтальная линия;

под горизонтальной линией – слова «ХАЛЫК ДРУЖИНАСЫ» прописными буквами высотой 60 мм.

Буквы изготавливаются термопечатью белого цвета.

2. Образец форменной одежды народного дружинника

**Фронтальная сторона**




**Тыльная сторона**



3. Нарукавная повязка народного дружинника представляет собой прямоугольник, изготовленный из ткани красного цвета, размером 250 х 100 мм с надписью по центру «ДРУЖИННИК» прописными буквами белого цвета высотой 25 – 40 мм, под ней горизонтальная линия, под линией надпись по центру «ДРУЖИНАЧЫ» прописными буквами белого цвета высотой 25 – 40 мм, длина надписей 150 – 200 мм, с фиксирующими элементами.

4. Образец нарукавной повязки народного дружинника



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

## 1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон "Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында" 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә кабул ителде һәм Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуын оештыруга бәйле мәсьәләләрне җайга сала.

2. Әлеге Закон халык дружиначысы таныклыгы үрнәген һәм аны бирү тәртибен, халык дружиначысының махсус символикасы үрнәген, халык дружиналарының координацияләү органнарын (штабларын) төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибен билгели.

## 2 статья. **Төп терминнар һәм төшенчәләр**

Әлеге Законда төп терминнар һәм төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

## 3 статья. **Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнар катнашуының хокукый нигезе**

Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнар катнашуының хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары, федераль конституциячел законнар, Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар тәшкил итә.

4 статья. **Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуын җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

1. Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуын җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуын җайга салу өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итә;

2) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм итә;

3) Татарстан Республикасында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча республика штабын төзи;

4) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында хәбәрсез югалган затлар, аларны эзләүнең якынча урыны турында гомуми файдалана алырлык мәгълүмат, хәбәрсез югалган затларны эзләү чаралары координаторларының контакт мәгълүматлары, хәбәрсез югалган затларны нәтиҗәле эзләү өчен кирәкле башка гомуми файдалана алырлык мәгълүмат урнаштыра;

5) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә мәгълүмати-методик ярдәм күрсәтә;

6) җәмәгать тәртибен саклау буенча эчке эшләр органнары (полиция) яисә башка хокук саклау органнары тарафыннан уздырыла торган чараларда катнашу чорына халык дружиначыларын шәхси иминләштерүне гамәлгә ашыра;

7) җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуын җайга салу өлкәсендә федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкара.

2. Әлеге статьяда билгеләнгән вәкаләтләрне башкару тәртибе законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5 статья. **Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнар катнашуын җайга салу өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә Федераль законда, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда, әлеге Законда һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә ярдәм итә, халык дружиналарының эшчәнлеге өчен шартлар тудыра.

2. Хәбәрсез югалган затларны эзләүдә катнашучы гражданнарга булышу максатларында җирле үзидарә органнары "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзләренең рәсми сайтларында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында хәбәрсез югалган затлар, аларны эзләүнең якынча урыны турында гомуми файдалана алырлык мәгълүмат, хәбәрсез югалган затларны эзләү чаралары

координаторларының контакт мәгълүматлары, хәбәрсез югалган затларны нәтиҗәле эзләү өчен кирәкле башка гомуми файдалана алырлык мәгълүмат урнаштыра.

Мондый мәгълүматны урнаштыру тәртибе муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

3. Җирле үзидарә органнары, хәбәрсез югалган затларны эзләүдә оештырылган төркемнәр төзү, эзләүнең якынча маршрутын һәм урынын билгеләү мәсьәләләрен, башка мәсьәләләрне хәл итү өчен, хәбәрсез югалган затларны эзләүдә катнашучы гражданнарга җирле үзидарә органнарының тәкъдимнәрен юллау тәртибен билгели.

4. Татарстан Республикасында тиешле муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары халык дружинасы төзелергә мөмкин булган территориянең чикләрен билгели.

5. Җирле үзидарә органнары халык дружиналары эшчәнлеген матди-техник тәэмин итүне финанслауга акча бүлеп бирергә, халык дружиналарына биналар, аларның эшчәнлеген башкару өчен кирәкле техник һәм башка матди чаралар бирергә мөмкин.

6. Җирле үзидарә органнары тиешле бюджетлар акчалары исәбеннән халык дружиначыларының эшчәнлеген матди кызыксындырырга, халык дружиначыларына муниципаль берәмлек территориясе чикләрендә шәһәр, шәһәр яны һәм җирле җәмәгать транспортының барлык төрләре өчен (таксидан тыш) йөрү билетлары бирергә, халык дружиначыларына һәм аларның гаилә әгъзаларына өстәмә ташламалар һәм компенсацияләр, хокукый һәм социаль яклау гарантияләрен билгеләргә, шулай ук матди кызыксындыруның Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка рәвешләрен кулланырга мөмкин.

Җирле үзидарә органнары тарафыннан халык дружиначыларына ташламалар һәм компенсацияләр бирү тәртибе муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

6 статья. **Халык дружиналарын координацияләү органнары (штаблар)**

1. Татарстан Республикасы территориясендә халык дружиналарының эшчәнлеген координацияләүне һәм аларның Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук эчке эшләр органнары (полиция) һәм башка хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлеген гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча республика штабы (алга таба – Республика штабы) төзелә.

2. Республика штабы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелә һәм даими эшләүче коллегиаль орган булып тора. Республика штабының структурасын һәм составын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый.

3. Республика штабының төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) халык дружиналары эшчәнлеген җәмәгать тәртибен саклауда эчке эшләр органнарына (полициягә) һәм башка хокук саклау органнарына ярдәм итү мәсьәләләре буенча координацияләү;

2) халык дружиналары эшчәнлеге турында мәгълүматны гомумиләштерү һәм анализлау һәм Татарстан Республикасында халык дружиналары командирлары өчен өйрәтү семинарлары уздыру;

3) эчке эшләр органнарына (полициягә) һәм башка хокук саклау органнарына җәмәгать тәртибен саклауда ярдәм итү мәсьәләләре буенча халык дружиналары өчен тәкъдимнәр эшләү;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән башка бурычлар.

4. Төп бурычларны үтәү максатларында Республика штабы түбәндәге функцияләрне башкара:

1) халык дружиналары эшчәнлеген координацияләүгә һәм эчке эшләр органнарына (полициягә) һәм башка хокук саклау органнарына җәмәгать тәртибен саклауда ярдәм итүгә бәйле мәсьәләләрне һәм тәкъдимнәрне карау;

2) үз компетенциясе чикләрендә карарлар кабул итү;

3) халык дружиналары командирларына, аларның урынбасарларына таныклыклар ясау, тапшыру һәм ул таныклыкларны алмаштыру;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән башка функцияләр.

5. Тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә халык дружиналарының үзара хезмәттәшлеге һәм аларның эшчәнлеген координацияләү максатларында җирле үзидарә органнары халык дружиналарын координацияләү органнары (штаблар) төзергә мөмкин.

6. Халык дружиналарын координацияләү органнарын (штабларны) төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибе әлеге Законга 1 нче кушымтада билгеләнә.

7 статья. **Халык дружиначысының таныклыгы һәм махсус символикасы**

1. Халык дружиначысы җәмәгать тәртибен саклауда катнашканда әлеге Законга 2 нче һәм 4 нче кушымталар нигезендә форма киеме һәм (яисә) кул повязкасы рәвешендә халык дружиначысының махсус символикасын кулланырга һәм билгеләнгән үрнәктә ясалган халык дружиначысы таныклыгын үзендә йөртергә тиеш.

2. Халык дружиначысы таныклыгын бирү тәртибе әлеге Законга 3 нче кушымтада билгеләнә.

3. Халык дружиначысының форма киеме җәмәгать тәртибен саклау чараларында катнашканда халык дружиначысы киеп йөрү өчен каралган өс киеменең күренеп тора торган бертөрле тышкы билгеләр булган элементыннан гыйбарәт.

4. Халык дружиначысына форма киеме һәм (яисә) кул повязкасы дежурлыкка керешкәндә халык дружинасы командиры тарафыннан бирелә.

5. Халык дружинасында әгъза булуны туктатканда яисә таныклыкның гамәлдә булу вакыты чыккан очракта таныклык халык дружинасы командирына тапшырылырга тиеш.

6. Халык дружиначысы таныклыгы, форма киеме һәм кул повязкасы халык дружиналары акчалары исәбеннән әзерләнә.

8 статья. **Халык дружиначыларын матди кызыксындыру һәм шәхси иминләштерү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән халык дружиначылары эшчәнлеген матди кызыксындыруны гамәлгә ашырырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты җәмәгать тәртибен саклау буенча эчке эшләр органнары (полиция) яисә башка хокук саклау органнары тарафыннан уздырыла торган чараларда катнашу чорына халык дружиначыларын шәхси иминләштерүне гамәлгә ашыра.

3. Иминият суммалары халык дружиначысы җәмәгать тәртибен саклау буенча эчке эшләр органнары (полиция) яисә башка хокук саклау органнары тарафыннан уздырыла торган чараларда катнашу чорында түбәндәге иминият очраклары барлыкка килгәндә түләнә:

1) халык дружиначысы һәлак булса;

2) халык дружиначысына инвалидлык билгеләнсә;

3) халык дружиначысы тән җәрәхәтләре алса.

9 статья. **Җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнарны дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан бүләкләү чаралары**

1. Җәмәгать тәртибен саклауда һәм хокук бозуларга каршы көрәштә актив катнашкан өчен халык дружиначылары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан түбәндәгечә бүләкләнергә мөмкин:

1) рәхмәт белдерү;

2) акчалата премия бирү;

3) кыйммәтле бүләк тапшыру;

4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының мактау грамоталары, җирле үзидарә органнарының мактау грамоталары белән бүләкләү.

2. Җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнар иҗтимагый бурычларын үтәгәндәге аерым казанышлары, шул чакта күрсәткән батырлыклары һәм каһарманлыклары өчен законнар нигезендә Россия Федерациясе дәүләт бүләкләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә тәкъдим ителергә мөмкин.

3. Бүләкләүләр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле бюджетлар акчаларыннан, физик һәм юридик затларның ихтыярый иганәләреннән һәм законнарда тыелмаган башка чыганаклардан бирелә.

10 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану**

Әлеге Закон үз көченә кергән көннән түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) “Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында” 2005 елның 1 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын;

2) “Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында” 2007 елның 8 ноябрендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын;

3) “Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында” Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында” 2008 елның 23 июнендәге 25-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын;

4) “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясын.

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып алты ай эчендә аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 16 гыйнвары
№ 4-ТРЗ

“Татарстан Республикасында
җәмәгать тәртибен саклауда
гражданнарның катнашуы турында”
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

**Халык дружиналарын координацияләү органнарын (штабларны) төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибе**

1. Федераль законның 13 статьясы нигезендә әлеге Тәртип халык дружиналарын координацияләү органнарын (штабларны) төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибен билгели.

2. Халык дружиналарын координацияләү органнары (штаблар) халык дружиналарының үзара хезмәттәшлеге һәм аларның эшчәнлеген координацияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелергә мөмкин.

3. Халык дружиналарын координацияләү органын (штабны) төзү турында карар, аның составын раслау бу органны төзү турында карар кабул иткән органның хокукый акты белән рәсмиләштерелә.

4. Халык дружиналарын координацияләү органы (штаб) үз эшчәнлеген аны төзү турында карар кабул иткән орган раслый торган нигезләмә буенча башкара.

5. Халык дружиналарын координацияләү органы (штаб) составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, башкарма хакимиятнең эчке эшләр өлкәсендәге федераль органының территориаль органы вәкилләре, шулай ук хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләре һәм халык дружиналары командирлары кертелергә мөмкин. Халык дружиналарын координацияләү органы (штаб) составына кирәк булганда башка затлар да кертелә ала.

6. Халык дружиналарын координацияләү органын (штабны) халык дружиналарын координацияләү органы җитәкчесе (штаб башлыгы) җитәкли, ул халык дружиналарын координацияләү органын (штабны) төзү турында карар кабул иткән органның вазыйфаи затлары арасыннан билгеләп куела.

7. Халык дружиналарын координацияләү органы (штаб) түбәндәгеләрне башкара:

а) халык дружиналарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм хокук саклау органнары белән җәмәгать тәртибен саклау мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеген оештыра;

б) халык дружиналары эшчәнлегенең төп мәсьәләләрен карый, халык дружиначылары эше вакытында килеп чыга торган мәсьәләләрне ачыклый, аларны хәл итү өчен тәкъдимнәр эшли;

в) үз эшенә кызыксынучы органнар һәм оешмалар вәкилләрен, башка белгечләрне җәлеп итә;

г) законнар нигезендә башка вәкаләтләр башкара.

“Татарстан Республикасында
җәмәгать тәртибен саклауда
гражданнарның катнашуы турында”
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**Халык дружиначысы таныклыгы тасвирламасы һәм үрнәге**

1. Халык дружиначысы таныклыгы 65 х 200 мм үлчәмдәге (ачык килеш) китапчыктан гыйбарәт. Таныклыкның тышы кызыл төстәге материалдан ясала.Таныклыкның эчке ягына ак төстәге кәгазь ябыштырыла.

2. Таныклык тышының уң ягында өске өлештә алтынсу төстәге баш хәрефләр белән ике юлга

“ХАЛЫК ДРУЖИНАЧЫСЫ
ТАНЫКЛЫГЫ” дип языла,

астарак алтынсу төстә горизонталь линия сызыла.

Күрсәтелгән горизонталь линия астына алтынсу төстәге баш хәрефләр белән ике юлга

“УДОСТОВЕРЕНИЕ
НАРОДНОГО ДРУЖИННИКА” дип языла.

3. Таныклыкның эчке ягында сул якта:

өстә бер горизонталь линия, аның астына “(халык дружинасының исеме)” сүзләре языла;

алар астында уртада – “ХАЛЫК ДРУЖИНАСЫ” сүзләре языла;

алар астында уртада – “Таныклык № ___” сүзләре языла;

аскарак өч юлга “Фамилиясе”, “Исеме”, “Атасының исеме” сүзләре языла, һәрбер юл янәшәсендә уң якка горизонталь сызык сызыла;

күрсәтелгән сүзләрдән аста бер горизонтальдә ике линия сызыла, сулдагысы астына – “(вазыйфасы)”, уңдагысы астына “(имза”) сүзе языла;

астагы өлештә ике юлга түбәндәге сүзләр языла:

“20 ___ елның ______ кадәр гамәлдә
“20 ___ елның ______ кадәр озайтылды”.

4. Таныклыкның эчке ягында уң якта:

өстә уртада – “НАРОДНАЯ ДРУЖИНА” сүзләре;

алар астында бер горизонталь линия сызыла, аның астына “(халык дружинасы исеме)” сүзләре языла;

алар астында уртада – “Удостоверение № ___” сүзләре языла;

күрсәтелгән сүзләрдән аста 2,5 х 3 см зурлыкта фоторәсем (анфас) ябыштырыла;

фоторәсемнән унда өч юлга “Фамилия”, “Имя”, “Отчество” сүзләре языла, һәрбер сүз янәшәсендә уң якка горизонталь сызык сызыла;

күрсәтелгән сүзләрдән аста бер горизонтальдә ике линия сызыла, сулдагысы астына – “(должность)”, уңдагысы астына “(подпись”) сүзе языла;

фоторәсем астында мөһер өчен урын калдырыла һәм “М.П.” баш хәрефләре куела;


астагы өлештә ике юлга түбәндәге сүзләр языла:

“Действительно до _____20 ___ года

Продлено до _______20 ___ года”.

5. Кирәкле барлык реквизитларны тутырганнан соң таныклык җирле үзидарә органы мөһере белән таныклана: мөһер фоторәсемнең астагы сул почмагы һәм халык дружинасы командиры имзасы куелган юл өстенә сугыла.

6. Халык дружиначысы таныклыгы үрнәге




**Эчке якның сул өлеше** | **Эчке якның уң өлеше**

| Эчке якның сул өлеше | Эчке якның уң өлеше |
| --- | --- |
| ______________________ (халык дружинасының исеме) | НАРОДНАЯ ДРУЖИНА |
| ХАЛЫК ДРУЖИНАСЫ | ______________________ (наименование народной дружины) |
| Таныклык № ____ | место для фотографии Удостоверение № _____ |
| Фамилиясе ____________ | Фамилия ____________ |
| Исеме ____________ | Имя ____________ |
| Атасының исеме ____________ | Отчество ____________ |
| ________ (вазыйфасы) ________ (имза) | М.П. ________ (должность) ________ (подпись) |
| 20 ____ елның ________ кадәр гамәлдә | Действительно до ________ 20 ____ года |
| 20 ____ елның ________ кадәр гамәлдә | Продлено до ________ 20 ____ года |

“Татарстан Республикасында
җәмәгать тәртибен саклауда
гражданнарның катнашуы турында”
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**Халык дружиначысы таныклыгын бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Федераль законның 16 статьясы нигезендә халык дружиначысы таныклыгын бирү тәртибен билгели.

2. Халык дружиначысы таныклыгын рәсмиләштерү “Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында” Татарстан Республикасы Законы белән расланган бердәй үрнәк буенча җирлекләрнең, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан башкарыла.

3. Халык дружиначысы таныклыгы, гражданның язмача гаризасына нигезләнеп, өч елга бирелә.

Таныклыкның гамәлдә булу вакыты өч елга озайтыла.

4. Халык дружиначысы таныклыгы җирле үзидарә органының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана һәм җирле үзидарә органы мөһере белән таныклана.

5. Халык дружиначысы таныклыгы халык дружиначысына, аның имзасын алып, кагыйдә буларак, тантаналы рәвештә һәм халык дружинасы әгъзалары катнашында тапшырыла.

6. Җирле үзидарә органы бирелгән таныклыкларның исәбен халык дружиначылары таныклыкларын теркәү журналында алып бара.

7. Халык дружиначысы таныклыгы югалган яисә бозылган, аның гамәлдә булу срогы тәмамланган яисә халык дружиначысының персональ мәгълүматлары үзгәргән очракта таныклык алмаштырыла. Мондый очракта элек бирелгән таныклык (югалган очраклардан тыш) халык дружинасы командиры тарафыннан тиешле җирле үзидарә органына тапшырыла.

8. Халык дружиначысын халык дружинасыннан чыгарган очракта халык дружиначысы таныклыгы халык дружинасы командиры тарафыннан тиешле җирле үзидарә органына кире тапшырыла.

“Татарстан Республикасында
җәмәгать тәртибен саклауда
гражданнарның катнашуы турында”
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

**Халык дружиначысының махсус символикасы тасвирламасы һәм үрнәге**

1. Халык дружиначысының форма киеме яктылыкны кире кайтаргыч өлешләр тегелгән зәңгәр төстәге жилеттан гыйбарәт, аңа түбәндәге язулар төшерелгән:

1) алда уң якта күкрәк кесәсе тигезлегендә – 10 мм зурлыктагы баш хәрефләр белән “НАРОДНАЯ ДРУЖИНА” сүзләре;

2) алда сул якта күкрәк кесәсе тигезлегендә – 10 мм зурлыктагы баш хәрефләр белән “ХАЛЫК ДРУЖИНАСЫ” сүзләре;

3) артта – 60 мм зурлыктагы баш хәрефләр белән “НАРОДНАЯ ДРУЖИНА” сүзләре;

алар астында горизонталь линия;

горизонталь линия астында – 60 мм зурлыктагы баш хәрефләр белән “ХАЛЫК ДРУЖИНАСЫ” сүзләре.

Хәрефләр ак төстәге термоысул белән төшерелә.

2. Халык дружиначысының форма киеменең үрнәге

**Алгы як**




**Арткы як**



3. Халык дружиначысының кул повязкасы кызыл төстәге тукымадан тегелгән 250 x 100 мм зурлыктагы турыпочмаклыктан гыйбарәт, аның уртасына 25 – 40 мм зурлыктагы ак төстәге баш хәрефләр белән “ДРУЖИННИК” дип языла, аның астында горизонталь линия сызыла, линия астына уртага 25 – 40 мм зурлыктагы ак төстәге баш хәрефләр белән “ДРУЖИНАЧЫ” дип языла, язуның озынлыгы 150 – 200 мм тәшкил итә, бәйләп кую өчен каралган өлешләре була.

4. Халык дружиначысының кул повязкасының үрнәге

